**СОВЕТ СТОЛБИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 с.Столбище,
ул. Советская, д.103
тел: 4-12-91

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СТОЛБИЩЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422624 Столбище авылы,
Совет урамы, 103 нче йорт,
тел: 4-12-91

---

**2024лның 11 декабре** **80/2 номер**

## КАРАР

### Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең Усад авылы торак пунктында (Цветочная, Лесная, Парковая, Березовая, Липовая, Радужная, Малая радужная, Лиственная урамнары территориясендә) 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында гражданнар җыены карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 8 декабрендәге «2025 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең Усад авылы торак пунктында (Цветочная, Лесная, Парковая, Березовая, Липовая, Радужная, Малая радужная, Лиственная урамнары )территриясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 10000 сум күләмендә ризалыгыгыз бармы, моңа балачактан көндезге формада белем алучы студентлар һәм инвалидларны исәпкә алмыйча, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны-

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү буенча эшләр өчен түләүгә юллау белән килешәсезме дигән сорау буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

-сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 142 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 120 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында 120 катнашучы «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

"Каршы" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

“Тавыш бирмәде” – 0 кеше.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Усад авылы торак пунктында (Цветочная, Лесная, Парковая, Березовая, Липовая, Радужная, Малая радужная, Лиственная урамнары торак пункты территориясенең бер өлеше) гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип таныргa.

2. Усад авылы торак пунктында (Цветочная, Лесная, Парковая, Березовая, Липовая, Радужная, Малая радужная, Лиственная урамнары территориясенең бер өлеше) территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда үзара салым акчаларын 10000 сум күләмендә кертергә. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү буенча эшләр өчен түләүгә юллау белән килешәсезме дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Столбище авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең әлеге карарын Столбище авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Столбище**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы: _________________ И.Ю.Романова**